**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**БАЛЫК БИСТӘСЕ**
**МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ**
**«ЮЛСУБИНО ТӨП**
**ГОМУМИ БЕЛЕМ МӘКТӘБЕ»**
**ГОМУМИ БЕЛЕМ МУНИЦИПАЛЬ**
**БЮДЖЕТ УЧРЕЖДЕНИЕСЕ**

# “Намуслы кеше – бәхетле кеше”.

( 4 нче сыйныфта тәрбия сәгате)

(Укытучы Сәлахиева Д.Г)

**Максат:** намус, оят кебек әхлак төшенчәләренең мәгънәләрен ачыклау;

үзеңнең эш-гамәлләреңә үзбәя бирә белү, уйлану,әхлакый

яктан идеал кеше булырга омтылу,коррупция сүзенең мәгънәсе

аңлату.

**Җиһазлау**: проектор, экран, компьютер.

**Барышы.**

**1слайд – исеме.**

**2 слайд – максат.**

-Хәерле көн, укучылар. Бүгенге тәрбия сәгатебезне “Намуслы кеше - бәхетле кеше” дип атадым. Бу чынлыкта да шулаймы, сез моның белән килешәсезме, гомумән, нәрсә соң ул намус, бармы ул, кайда туа, кеше өчен кирәкле сыйфатмы кебек сорауларга җавап табарга тырышырбыз.

“Антикоррупциягә-юл ябык” дигән тема иттереп тә алырга булыр иде бүгенге темабызны,әмма мин сезгә бу сүзнең нинди мәгънәне аңлатканын гына бераз аңлатып китәм.

Илебездәге 100дәүләт 2003елның 9 декабрендә коррупциягә каршы Конвенциягә кул куя башлый.Шул көннән башлап,бу Халыкара документ үз көчендә кала бирә.

Коррупция=латинча сүз,юридик термин түгел,эш урыныннан явызларча файдалануны аңлата.Коррупция белән теләсә кем шөгыльләнә ала,тик бу кешеләр җәмгыятькә файдалы кешеләр түгел,куркыныч кешеләр.Намусын югалтканнар гына мондый адымга бара ала.Кытайда хәтта бу эш белән шөгыльләнгән өчен атып үтерү каралган.

-Бүгенге тәрбия сәгатебез белән бәйле бер хәл сөйләп китим әле үзегезгә.Тыңлап карагыз әле. Сездә нинди фикерләр уятыр икән әлеге хикәям?

“ Бервакыт яшь кенә бер егет урамнан барганда юл кырыенда хәер сорашып утыручы сукыр кешегә юлыга. Алдында тимер кружкада тиен акчалар. Әллә егетнең кәефсез чагы туры килә, әллә белмәссең яшьләрне... Ул иелеп пыяла ватыклары ала да, кружкага ыргыта. Һәм үз юлы белән китеп бара.

Әлеге вакыйгадан соң 50 ел гомер үтә. Егетебез чал чәчле ирләр рәтенә керүче абый кешегә әйләнә. Тормышта барысына да ирешә. Гаилә, балалар, оныклар, хөрмәт, байлык-бар да бар. Ләкин йөрәк кенә тынычлык бирми. Ничә еллар узуга карамастан, теге пыяла

кыйпылчыклары тынгы  бирми аңа. Намус дигән нәрсә көн дә аның алдына сорау куя. Һәм ул теге кешене эзләп табып, яшьлек хатасы өчен гафу үтенергә була. Үзе туып-үскән шәһәргә килә, таныш урамда басып тора. Ә сукыр һаман шул урында, шул ук тимер кружкасы белән утыра.

- Хәтерлисеңме, күп еллар элек синең шушы тимер кружкаңа кемдер пыяла ватыклары ыргытып киткән иде, ул – мин,- диде.
- Ул пыяла ватыкларын мин шул көнне үк ташладым, ә син аларны 50 ел буе йөрәгеңдә йөрткәнсең,- диде сукыр.”

**Пауза.**

-Озак еллар буе иргә нәрсә тынычлык бирми?

-Сез хикәягә нинди исем бирер идегез?(исемнәр тактага языла).

- Намус сүзен ничек аңлыйсыз? Җавапларыгызны эчтән әзерли, уйлый торыгыз. Һәр кешенең җавабы төрле булырга мөмкин,каршылыклы фикерләр дә булыр. Шуңа күрә ,әйдәгез әле, бергәләшеп кагыйдәләрне искә төшереп үтик.

**3 слайд – кагыйдәләр.**

1. ***Үз фикереңне әйт, кешенекен кабатлама.***
2. ***Фикерләрнең күбрәк булуы яхшы.***
3. ***Фикерләр бәяләнми, тәнкыйтьләнми.***
4. ***Һәр кешенең фикере тыңлана, кабул ителә.***

**4 слайд – Намус төшенчәсенә аңлатма.**

-Намус, минемчә, абстракт төшенчә, аны тотып та, ашап та, күреп тә, иснәп тә карап булмый. Аны бары кешенең йөрәге тоя, сизә.

Укучыларныә фикерләре тыңлана.

-Намус турында татар халкында бик үтемле әйтемнәр бар. Шуларга күз салыйк әле. Ничек аңлыйсыз?

**5 слайд - әйтемнәр**

**Акчаң булмаса да, намусың булсын.**
**Намусны су юа алмый.**
**Намуслы йөз ояла.**
**Намусы пакь – йөзе ак.**
**Намусыңны яшьтән сакла.**

## 6 слайд – “Намус авазы”

-Кеше һәрвакыт сайлау алдында тора. “Намус авазы” өлешендә, ситуацияләр чишүдә, нинди юл сайларсыз икән?

**Кагыйдәләр искә төшерелә.**

1.Сез кибеттә.Күрәсез, идәндә бер мең акча ята. Хуҗасы юк. Нишлисез?(1 рәткә) –үзем белән булган хәлне сөйләргә –вакыт калса)

2.Сыйныфта шау-шу күтәрелә. Кемдер стенага сызгалаган.Сыйныф җитәкчесе гаепле кешене эзли. Берәү дә дәшми. Гаеплене сез беләсез,ул-якын дустыгыз. Нишлисез?.(2 рәткә)

-Ничек уйлыйсыз, намусың йокламасын өчен нишләргә кирәк?

-Дөрес. Аны һәрвакыт хәрәкәтләндереп торырга кирәк. Аның белән сөйләшергә, киңәшләшергә кирәк.

-Үзегезгә сорау биреп карагыз әле, “намусыгыз йоклыймы, уяумы?”

-Чарабыз ахырында бер кечкенә генә әкият сөйлим әле.
“Кышкы аяз иртәдә Хуҗа өеннән чыккан. Күрә, ап-ак кар өстендә алар өеннән чыккан аяк эзләре. Кем булыр бу? Хуҗа эз буенча китә. Урманга җитәрәк бер куакта нидер кыштырдый.
-Син кем?- дип сорый Хуҗа.
-Бәхетең. Сезнең өйдә хәзер гел байлык турында гына сөйләшәләр. Мин сезгә кирәкмим, шуңа киттем. Ләкин китәр алдыннан,сезнең бер теләгегезне үти алам.
Хуҗа өйдәгеләре белән киңәшергә булган. Кемдер матур кием, алтын-көмеш, тәмле ашау теләгән.Тик бер читтә басып торучы килен кеше:”Намус сорарга кирәк”,-дигән. Хуҗа шулай эшләгән.
-Бар нәрсәбезне ал, тик намусыбызга кагылма,- ди.
Бәхет елмая һәм:
-Алайса, мин дә калам. Намуслы йортта гына яши бит бәхет, -ди Бәхет.

“Уч төбе”уенын уйнап,класс сәгатебезне төгәллибез,балалар.Уенның шарты болайрак:һәрберегез кәгазьгә үзегезнең уч төбегезне төшереп,уртага-исемегезне,бармакларга үзегездәге иң күзгә ташланган сыйфатларыгызны язып куегыз әле.Сез үзегезне әйбәт беләсездер дип  уйлыйм.Хәзер ясаган уч төпләрегезгә карап,нәтиҗә ясагыз,балалар.Биредә барысы да ачык күренә.Мин киләчәктә сезнең намуслы кешеләр булып,туры юлдан,тайпылмыйча баруыгызны телим,сезнең белән ачыктан-ачык сөйләшүемә шатмын.

- Сезнең һәркайсыгызның намуслы һәм бәхетле булып яшәвегезне телим.

**7 слайд – Катнашуыгыз өчен рәхмәт**